СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

2015 елның «12» февраленнән № 41-240

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләрнең башлангыч (минималь) бәясен исәпләү тәртибе һәм бер квадрат метр реклама кыры бәясенең база тарифын раслау турында»**

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләрен, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә карата милек хокукын һәм (яисә) мөлкәтнең төрләрен көчүне күздә тоткан башка шартнамәләрне һәм әлеге килешүләрне төзү карата конкурс рәвешендә сату итү юлы белән башкарылырга мөмкин булган мөлкәт төрләренең исемлеген төзү хокукына конкурслар яки аукционнар үткәрү тәртибе турында» Федераль монополиягә каршы хезмәтнең 2010 елның 10 февралендәге 67 номерлы боерыгы нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Бер квадрат метр реклама кыры бәясенең база тарифын аена 50 сум күләмендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләрнең башлангыч (минималь) бәясен исәпләү тәртибен расларга.
3. Карарның үтәлешен Яңа Чишмә муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.
4. Әлеге карар «Шешминская Новь», «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасында һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырылырга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципального района В. М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2015 елның «12» февраленнән
41-240 номерлы карарына
кушымта

**Реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү килешүенең башлангыч (минималь) бәясен исәпләү тәртибе**

Аерым реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү, дивар панносы өчен Шартнамәнең башлангыч (минималь) бәясе күләме формула буенча билгеләнә: С = БТ Х Sк К2 Х К3 (елына), монда:

БТ - реклама кырының бер квадрат метр бәясенең база тарифы.
S - реклама конструкциясенең мәгълүмати кырының гомуми мәйданы (кв. м.);
К] - территориаль бәйләнешне исәпкә ала торган коэффициент. Аның әһәмияте 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица.

| № т/б | Территориаль зона. Зона тасвирламасы | Коэффициент күрсәткече |
|---|---|---|
| 1 | Зона 1.<br>Яңа Чишмә авылының үзәк урамнары (Ленин ур., Чернышевский ур., Совет ур.) | 1,2 |
| 2 | Зона 2.<br>Зона 1 урамнары исемлегенә кермәгән торак пунктлар урамнары | 1 |
| 3 | Зона 3. Федераль һәм республика юлларының юл буйлары | 0,8 |

К2 - реклама кыры мәйданын исәпкә ала торган коэффициент Аның курсәткече 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче Таблица.

| № т/б | Мәгълүмат кырларының мәйданы, кв.м | Коэффициент күрсәткече |
|---|---|---|
| Аерым торучы реклама конструкцияләре өчен | | |
| 1 | 6га кадәр, аны да кертеп | 1,5 |
| 2 | 6дан 15кә кадәр, аны да кертеп | 1,2 |
| 3 | 15 тән алып 30 кадәр, аны да кертеп | 1 |
| 4 | 30 артык | 0,8 |
| Стена паннолары өчен | | |
| 5 | 10га кадәр 10ны кертеп | 0,6 |
| 6 | 10 дән артык | 0,4 |

$K_3$- реклама конструкциясенең тибын исәпкә ала торган коэффициент. Аның күрсәткече 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче Таблица.

| № т/б | Реклама кыры үтәлеше тибы | Коэффициент күрсәткече |
|---|---|---|
| 1 | Электрон таблолар, видео экраннар, светодинамик конструкцияләр | 2 |
| 2 | Сурәтнең механик алмашынуы белән конструкцияләр | 1,5 |
| 3 | Башка төрләр | 1 |